| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Зур Тигәнәле авылы **КАРАР**

30.10.2019 № 6

**“Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлегенең**
**Зур Тигәнәле авылында үзара салым кертү**
**һәм гражданнарның үзара салым**
**акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын билгеләү турында”**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**карар бирәм:**

1.Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегенең Зур Тигәнәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 10 нчы ноябре көнне 13 сәгать 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
“Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегенең Зур Тигәнәле авылында 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, үзара салымны, барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән, балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, 1 нче төркем инвалидлар, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны түбәндәге җирле мәсәләләрне:

- Зур Тигәнәле авылында авыл эчендәге юлларга таш җәю, төзекләндерү һәм карап тотуны хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы?

ӘЙЕ КАРШЫ”

3.Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4.Җыенның үткәрү урыны дип Зур Тигәнәле авыл мәдәният йортын билгеләргә. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы, 17 нче йорт.

5.Әлеге карарны Зур Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы, 17 нче йорт.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.Җ.Әхмәтҗанов**